

Халыкара хатын-кызлар коне алдыннан Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Ижтимагый совет инициативасы белән «Леди в погонах» конкурсы узды.
Быел ярышларда регионыбызнын Эчке эшләр территориаль органнарынын һәм Эчке эшләр министрлыгынын Мордовия Республикасы буенча бvлекчәләренен 27 искиткеч хезмәткәре катнашты.
Конкурснын беренче этабында Эчке эшләр министрлыгынын рәсми торкемендә ВКонтакте социаль челтәрендә онлайн-тавыш бирv оештырылды.
Тавыш бирv нәтижәләре буенча финалга биш кыз чыкты. Конкурснын икенче этабы кысаларында финалистлар Макаров пистолетын тулысынча сvтеп-жыю нормативын vтәделәр, шулай ук жюри судына видеоролик-визиткалар тәкъдим иттеләр.
Нәтижәдә, «Леди в погонах - 2023» топ титулын Янислава Косолапова яулый. «Погоннарда беренче вице-леди - 2023» - Ирина Лысякова, «Погоннарда вице-леди-2023» титулына Юлия Кобзева лаек була, «Леди грация» титулын Александра Васина, «Леди Вдохновение» («Илһам ханым») титулын татар кызы - Эчке эшләр министрлыгынын жәмәгать тәртибен саклауны оештыру бvлеге инспекторы, полиция капитаны Рәсим кызы Гульнара Янгличева яулады. Жинvчегә һәм призерларга лаеклы бvләкләрне Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министры полиция генерал-майоры Юрий Поляков тапшырды, дип хәбәр итә ведомствонын матбугат хезмәте.
Гульнара Рәсим кызы Янгличева безгә таныш. Ул Мордовия Республикасы Ләмберә районы Ләмберә авылында туган һәм бvгенге конгә кадәр анда яши. Анын гаиләсен полицейскилар династиясе диярге була, чонки әтисе, абыйсы – хормәт яулаган хезмәткәрләр. Кечкенәдән бу профессия кешесе булырга хыялланган Гульнара Рәсим кызы югары уку йортын тәмамлаганнан сон, 2005 елда, милициягә эшкә килә. Анын әтисе, Ләмберәнен атаклы «Анискин»ы Рәсим Рәхмәтулла улы Курмаев, Эчке эшләр министрлыгы органнарында 23 ел хезмәт иткән подполковник әзләреннән бvген кызы Гульнара бара; ул vзе гомер буе Ләмберә бvлегендә эшли. Участоктан жәмәгать иминлеге милициясе начальнигына кадәр житә һәм полиция подполковнигы дәрәжәсендә отставкага китә. Әтисенә ошарга теләгән кызчык хезмәт биографиясендәге унышлары очен лаеклы бvләр белән бvләкләнә.
Гульнара Рәсимовна Янгличева оператив бvлекчәдә, участок подраз-делениесендә эшли һәм оч ел сак-конвой хезмәтенә бирә. Хәзер полиция капитаны дәрәжәсендә жәмәгать тәртибен саклау оешмасы идарәсендә хезмәт итә. Аралашучан, vз эшен яхшы белә һәм vз-vзенә ышана, кешеләр белән жинел аралаша һәм куелган максатларга ирешә ул. Хезмәт стажы 18 ел. Булачак Ватанны саклаучы улы Даниярны тәрбияли. Егеткә 14 яшь.

Татар жанлы «Илһам ханым» милли татар ризыкларын пешерергә һәм биергә ярата Гульнара Рәсим кызы. Безнен шундый полицейскиларыбыз булганга киләчәккә ышаныч ныгый.

**Наилә НАСЫРОВА**